# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Октябрь авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

16.11.2021 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2021нче елның 16 нчы ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2022 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Октябрь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә, I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 350 (өч йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.
-Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.
-Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.
-Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.
-Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.
-Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.
-Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

«РИЗА» - «КАРШЫ»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 198 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 106, бу 53,5% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 85 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 21 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Октябрь авыл җирлегенең Октябрь авылы торак пунктында гражданнар җыены узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Октябрь авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә,I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан 350(өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.

- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.

- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.

- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.

- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Октябрь авыл җирлеге башлыгы И.М Ханнанов